Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Күн авыл җирлеге Советы

Күн авыл җирлеге башлыгы
КАРАРЫ

«06» май, 2020 ел №4

Күн авыл җирлеге башлыгының 2020 елның 11 мартындагы 1 номерлы «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Күн авыл җирлеге генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү турында» гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Президентының (Яңа коронавирус йогышы (COVID-19) таралуга бәйле рәвештә, республикада махсус санитар-эпидемиология режимы кертелүгә бәйле рәвештә һәм гражданнар сәламәтлеге өчен хәвеф-хәтәрләр килеп чыкмасын өчен, Россия Федерациясе территориясендә халыкның санитар-эпидемиологик иминлеген тәэмин итү чаралары турында) 2002 елның 2 апрелендәге 239 номерлы Указы нигезендә **карар бирәм**:

1. Күн авыл җирлеге башлыгының 2020 елның 11 мартындагы 1 номерлы «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Күн авыл җирлеге генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү турында»гы карарына **түбәндәге үзгәрешләрне кертергә**:

- 3 пунктның 3.1.1 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«3.1.1. генераль планга үзгәрешләр кертү проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү датасы, вакыты һәм урыны:

- Күн авылында яшәүчеләр өчен: 2020 елның 14 маенда 10 сәгать 00 минутта Күн авыл мәдәният йорты фойесында (422790, ТР, Питрәч районы, Күн авыл җирлеге, Күн авылы, Совет урамы, 61а);

- Кызыл Яшьләр авылы халкы өчен: 2020 елның 14 маенда 12 сәгать 00 минутта Колхоз урамы буенча 10 нчы йорт янында (422790, ТР, Питрәч районы, Күн авыл җирлеге, Кызыл Яшьләр авылы, Колхоз урамы);

- Әлбәдән авылы халкы өчен: 2020 елның 14 маенда 14 сәгать 00 минутта (ФАП янындагы территория) (422790, ТР, Питрәч районы, Күн авыл җирлеге, Әлбәдән авылы, Күл урамы, 25а);»

- 5 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«5. Генераль планга үзгәрешләр кертү проекты буенча ачык тыңлауларга чыгарылган тәкъдимнәр һәм искәрмәләр, мәгълүмат басылганнан (халыкка җиткерелгәннән) һәм 2020 елның 13 маена кадәр (шул исәптән) кызыксынган затлар тарафыннан җирлек Башкарма комитетының электрон почтасына kon.pes@tatar.ru җибәрелергә мөмкин»

2. Питрәч муниципаль районының «Вперед» («Алга») район газетасында, рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) ачык тыңлаулар үткәрү турында мәгълүмат бастырырга (халыкка җиткерергә) һәм Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Күн авыл җирлегенең мәгълүмат стендлары урнаштырырга.

3. Әлеге карар аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Күн авыл җирлеге башлыгы Р.Г. Баhаувов